**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 22 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда 400 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Яңа Имән авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби оперциядә катнашучылардан , көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Яңа Имән авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

2) җәйге чорда территорияне чабу, (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

4) янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

5) Яңа Имән авылында күпләп ял итү урыннарын төзү һәм төзекләндерү (материаллар, сәхнәләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

6) Яңа Имән авылында «Махмурахман»,Зиннур» чишмәләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Яңа Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Гараев Р. Ф.Гараев